# ФИГЫЛЬ ТУРЫНДА КАБАТЛАУ

*Татар теле*

*4 класс*

Эшләде: Габдрахманова Наилә Шайнур кызы
Арча районы Түбән Мәтәскә урта мәктәбенең
I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

# Искә төшер!

Фигыль нәрсәне белдерә?
Ул нинди сорауларга җавап бирә?
Фигыльнең нинди төркемчәләре бар?
Фигыльләр нәрсә белән төрләнә?

# Фигыль

Хәзерге заман хикәя фигыль

Үткән заман хикәя фигыль

Киләчәк заман хикәя фигыль

# Хәзерге заман хикәя фигыль

Нишли?
-ый/ -и
-а/ -ә
Нишләми?
-мый/ -ми

укый – укымый
эшли – эшләми
бара – бармый
килә - килми

# Үткән заман хикәя фигыль

| Билгеле үткән заман | Билгесез үткән заман |
|---|---|
| Нишләде? | Нишләгән? |
| -ды/ -де | -ган/ -гән |

-ма/ -мә

| | |
|---|---|
| барды - килде | барган – килгән |
| бармады – килмәде | бармаган - килмәгән |

# Киләчәк заман хикәя фигыль

| Билгеле киләчәк заман | Билгесез киләчәк заман |
| --- | --- |
| Нишләр? | Нишләячәк? |
| -ыр/ -ер/ -р | -ачак/ -әчәк/ -ячак/ -ячәк |
| -мас/ -мәс | -ма/ мә |
| барыр – килер | барачак – киләчәк |
| бармас – килмәс | бармаячак - килмәячәк |

# Фигыльләрне зат – сан белән төрләндер.

Укыды, килде, кайтты, әйтте, барган, сөйләгән, утырткан, ишеткән,  яза, көрәшә, уйный, бии, сорар, китәр, явачак, эшләячәк, белмәс, уйламады.

Тиешле фигыльләрне куеп яз.

Кыштыр-кыштыр ... карабодай,
Туган-туфрак серле, хикмәтле:
Кочагына алып ... дә
... бер көн хәләл икмәкне.
Кояш ... . Офыклар ут ... .
Кызыл шәүлә ... алмада.
“Янгын!” –диеп, дәртле чикерткәләр
Берөзлексез кырда чаң ... .

Тирбәтә, үсә, байый, суза, бии, яна, кага.

# Табышмакларның җавапларын тап.

Утыра бер ак чүлмәк,
Өстенә кигән йөз күлмәк.

Җир астында җиз бүкән –
Һәр көн ашыйсың, иркәм.

Җир астында алтын казык.
Бик тәмле ул, ал син казып.

Сорыдыр төсе, үткендер теше;
Урманда йөри, сарыклар эзли.

Фигыльләрне тап, күчереп яз, тикшер.

Үрнәк: бара - хикәя фигыль, хәзерге заманда,
3 затта, берлектә, барлыкта.

Булдырдыгыз!